КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 05 июнь г.Казань № 429

«Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәмин итү һәм социаль яклау миистрлыгының Менделеевск муниципаль районындагы «Берег Надежды» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе структурасын оптимальләштерү турында

Социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 1 сентябреннән «Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәмин итү һәм социаль яклау миистрлыгының Менделеевск муниципаль районындагы «Берег Надежды» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең (алга таба – «Берег Надежды» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге) 23 койка-урынлы социаль-тернәкләндерү бүлеген бетерү турында тәкъдимен кабул итәргә

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә «Берег Надежды» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге тарафыннан әлеге учреждение структурасын оптимальләштерү буенча чаралар үткәрелгәндә хезмәткәрләргә карантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

календарь көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына оператив идарә итү хокукында «Берег Надежды» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтенең аерым төрләрен алга таба файдалану турында тәкъдимнәр тапшырырга, әлеге мөлкәт исемлеге белән;

«Берег Надежды» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге тарафыннан дәүләт биремен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә каралган чыгымнар өлкәсендә «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 елларның план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2017 елның 30 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында «Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча каралган акча кысаларында «Берег Надежды» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге структурасын оптимальләштерү белән бәйле чараларны үткәрүгә чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Календарь көннәрендә исәпләнгән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына законнарда билгеләнгән тәртиптә элек «Берег Надежды» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тапшырган мөлкәт исемлеге нигезендә тапшыруны тәэмин итәргә.

4. «Берег Надежды» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге структурасын оптимальләштерү чараларын үткәргәннән соң азат ителә торган акча Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт биремен (заказын) үтәүдә катнашмаган социаль хезмәтләр күрсәтүчеләргә халыкка социаль хезмәт күрсәтү тармагында социаль хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарын компенсацияләүгә (кайтаруга) субсидияләр рәвешендә гарантлар бирүгә юнәлтелә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыру максатында, шулай ук алар тәмамланганда 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 елларның план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язуына үзгәрешләр кертергә һәм «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 елларның план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2017 елның 30 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырырга.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, әлеге карарның 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән чаралар тәмамланганнан соң календарь көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмалары норматив чыгымнарын раслау турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 699 нчы карарына тиешле үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин